**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: mail.Aktanish@tatar.ru , www.aktanysh.tatarstan.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_27.06.2025___ № _ПР-138_

Махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр акчалата түләү бирү тәртибен раслау хакында

Аерым категориядәге гражданнар өчен социаль ярдәм күрсәтү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясындагы 5 пунктының 2 абзацы, Устав нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Актаныш районы хәрби комиссариаты аша махсус хәрби операциядә катнашу максатыннан Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер мәртәбә бирелә торган акчалата түләү бирү тәртибен (1 нче кушымта) расларга.
2. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының “ФБП” МКУнә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының хәрби комиссариаты аша махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр акчалата түләү бирүгә бәйле чыгымнарны ясарга.
3. Россия Федерациясе Оборона министрлыгыннан ТР Актаныш районы хәрби комиссариаты аша әлеге Нигезләмәнең 3.2, 3.3 пунктларында күрсәтелгән документларны алуны район Башлыгы ярдәмчесе А.Ф.Фәрдиевка йөкләргә(килешү буенча).
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Ш.Бариев

ТР АМР Башкарма комитеты
карарына ________№______
1 нче кушымта

ТР Актаныш районы хәрби комиссариаты аша махсус хәрби операциядә катнашу максатыннан Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү тәртибе

Махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүнең әлеге тәртибе (алга таба – Тәртип) ТР Актаныш районы хәрби комиссариаты аша махсус хәрби операциядә катнашу максатыннан Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү формасында ТР Актаныш муниципаль районы бюджетыннан аерым гражданнарга социаль ярдәмнең өстәмә чарасын билгеләү һәм гамәлгә ашыру күләмен, тәртибен һәм шартларын билгели.(алга таба-бер тапкыр түләү).

**1.Бер тапкыр түләнә торган түләү күләме**

1.1.Бер тапкыр түләнә торган түләү күләме - 150 000 (йөз илле мең) сум.

**2. Бер тапкыр түләнә торган түләү бирү шартлары**

2.1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә ТР Актаныш районы хәрби комиссариаты аша махсус хәрби операциядә катнашу максатыннан хәрби хезмәт үтү турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнарына бер тапкыр түләнә.

2.2. Бер тапкыр түләнә торган акча 01.05.2025 елдан 31.12.2026 ел аралыгында Контракт төзегән гражданнарга түләнә.

**3. Бер тапкыр түләү бирү тәртибе**

**3.1**. Бер тапкыр бирелә торган түләүне алу өчен ТР Актаныш районы хәрби комиссариаты аша Контракт (алга таба - контрактчы) төзегән Россия Федерациясе гражданы бер тапкыр бирелә торган түләү турында әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә форма буенча төзелгән гариза (алга таба — гариза) җибәрә.

3.2. Гаризада түбәндәгеләр күрсәтелә:

контрактчының фамилиясе, исеме, атасының исеме;

контрактчының шәхесен таныклый торган документ турында белешмәләр (төре, бирү датасы, реквизитлар);

ИНН;

контакт телефоны;

контрактчының туу датасы (дд.мм.гггг);

теркәлү урыны адресы һәм контрактчының яшәү урыны (булган очракта).

**3.3.** Гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының хәрби комиссариатыннан контракт төзү турында белешмә;

контрактчы паспортының аны теркәүне раслый торган бите күчермәсе, тору урыны буенча теркәлү турында таныклык (булган очракта);

ИНН күчермәсе;

СНИЛС күчермәсе;

бер тапкыр түләнә торган түләүне күчерү өчен контракт счетының банк реквизитлары белән бастырылуы;

РФ МО белән контрактның күчермәләре.

шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирү турында документ.

**3.4.** Бер тапкыр бирелә торган түләү түбәндәге очракларда кире кагыла:

тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 3.2. һәм 3.3 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве, шулай ук белә торып дөрес булмаган, ялган белешмәләр (документлар) тапшырылган очракта;

**3.5.** «Шәхси мәгълүматлар турында» 27.07.2006 ел 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә контрактчының конфиденциальлеге һәм шәхси мәгълүматларын яклау тәэмин ителә.

**3.6**. Әлеге Нигезләмәдә күрсәтелгән гариза һәм документлар хәрби хезмәткәр исеменнән, бер үк вакытта хәрби хезмәткәр белән туганлыкны раслаучы документларны күрсәтеп, гаиләнең хокукка сәләтле әгъзасы бирергә хокуклы.

Гариза вәкаләтле вәкил тарафыннан бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүче шәхесне раслаучы документны һәм ышанычнамәне күрсәтә. Күрсәтелгән документларның күчермәләре һәм (яисә) төп нөсхәләре гаризага кушып бирелә.

**3.7.** Акчалата түләү Контракт төзегән гражданнарның кредит оешмаларында ачылган счетларына документлар кергән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган 12 көн эчендә күчерелә.

Бер тапкыр бирелә торган
акчалата түләү бирү тәртибенә
1 нче кушымта

________________________________
(ФИО тулысынча, туу датасы),
___________________________________
___________________________________

паспорт мәгълүматлары:
______ ______________ ____________
номер, серия, кайчан бирелгән,
_______________________________________
_________,
кем тарафыннан бирелгән,  бүлекчә коды
___________________________________
___________________________________
___________________________________
прописка нигезендә адрес буенча
яшәүче:________________________
индекс, теркәү адресы
___________________________________
___________________________________

№ тел.
_______________________________________

№ ИНН
______________________________________

**Гариза**

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының ________ №___ «Махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнарга бер тапкыр түләнә торган акчалата түләү бирү тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә миңа бер тапкыр акчалата түләү бирүләрен сорыйм.

Банк реквизитлары, РФ МО белән Контракт һәм ИНН күчермәләре.

_________________________
_________________________
_________________________

Бер тапкыр бирелә торган
акчалата түләү бирү тәртибенә
2 нче кушымта

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык

Мин, _______________________________________________________________,
________________________________________ (ФИО),________________елгы,
сериясе паспорты ________ N ___________, бирелгән _____________________
_________________________________________________________________________
адресы:
_________________________________________________________________________
ТР Актаныш районы Башкарма комитеты карары _________№______ нигезендә махсус хәрби операциядә катнашу максатында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнарга бер мәртәбә бирелә торган акчалата түләү бирү максатларында шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә ризалык бирәм.

Әлеге ризалык бирелгән персональ белешмәләр гаризада һәм тапшырылган документларда күрсәтелгән күрсәткечләрне үз эченә ала, шул исәптән: фамилия, исем, атасының исеме; шәхесне таныклый торган документ турында белешмәләр (бирү датасы, реквизитлар); ИНН; СНИЛС; туу датасы; теркәү урыны адресы һәм яшәү урыны (тору урыны), кредит оешмасында акча түләүләрен күчерү өчен ачык хисап счетлары турында белешмәләр.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртү гамәлләренә түбәндәгеләр керә: шәхси мәгълүматларны җыю, системалаштыру, туплау, саклау, төгәлләштерү (яңарту, үзгәртү), алу, куллану, тапшыру (тарату, бирү, керү), шәхессезләндерү, блоклау, бетерү, юкка чыгару.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртү автоматлаштыру чараларын кулланмыйча гамәлгә ашырыла.

Килешү бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирүгә гариза биргән мизгелдән алып шушы ризалыгымны язма рәвештә кире алганчыга кадәр гамәлдә була.

_________________________________________________________________________
(имза, фамилия һәм инициаллар)
Килештерү датасы: "___"________ 20__ ел.